Төрки-татар сүз сәнгатенең озын-озак тарихы бар. Аның язуга теркәлеп, хәзергәчә сакланып калган өлеше генә дә соңгы ике мең еллап вакытны үз эченә ала. Ә инде телдән-телгә сөйләнеп, төрле үзгәреш-эверелешләр кичереп яшәгән күп кенә фольклор әсәрләр үзләренең тамырлары, иҗат ителешләре белән безнең эрага кадәрге меңъеллыкларга барып тоташа. Аларның кайберләре хәтта борынгы Кытай, Һиндстан, Иран, грек, латин телләрендәге чыганакларда теркәлеп калган [1; 7: 162].

Мәгълүм ки, «төрки» этнонимы V гасырда гына кулланыла башлый. Ә «татар» атамасы Кытай чыганакларында яңа эрага кадәр үк очрый. Бу хакта инглиз галиме Эдуард Паркерның XIX гасыр азакларында нәшер ителгән китабында шактый тулы язылган [2: 9]. Скиф, сармат, һун атамалы кабилә-кавемнәр составында да безнең борынгы әби-бабаларыбызның булуы тарихтан билгеле. «Төрки» этнонимын йөртүчеләр этник яктан үзләре дә бер генә төрле булмый. Алар арасында уйгыр, хәзәр, болгар, карлук, угыз, кыпчак, кимәк, башкорт һәм кайбер башка атамалы кавемнәрнең тереклек кылуы мәгълүм. Күпчелеге күчмә тормыш шартларында яшәгән бу халыклар еш кына тереклек урыннарын алыштырганнар, үзара аралашканнар, керешкәннәр. Шуның нәтиҗәсе буларак, гомумтөрки кысаларында, чагыштырмача яңа этник берәмлекләр дә оешкан. Угыз кавемнәре, мәсәлән, төрекмән, әзербайҗан, төрек телләрен, халыкларын шәкелләштерүдә төп рольне уйнаган. Евразия татарлары болгар, хәзәр, кыпчак, татар компонентлары кушылудан формалаша. Төрки кавемнәрнең рухи язмышында, тарихи яшәешендә Төрки, Уйгыр, Карахани, Кимәк, Хәзәр, Сәлҗүк, Кыпчак, Алтын Урда, Чыгытай, Госманлы, Россия, Советлар Берлеге кебек мәмләкәт-империяләр дә тирән эз калдыра. Дәүләтчелек идеясе, мәмләкәт һәм гавам мөнәсәбәтләре сүз сәнгатендә дә күп гасырлар буе эшкәртелеп килә. Мифологик ышанулар элеккеге рухи тормышта гаять мөһим урынны алып тора.

Хәзерге фәндә төрки язма әдәбиятын VI-IX гасырларга мөнәсәбәтле рун истәлекләреннән башлап китү кабул ителгән. Дөрес, әле бу төр ядкәрләр саф әдәби әсәр түгел, алар тарихи, сәяси, дини һәм кайбер башка башлангычларның кушылмасы, синтезы рәвешендә. Шулай да, борынгы рун истәлекләрендә сүз сәнгатенә хас күренешләр һәм элементлар шактый күзәтелә. Арада хәтта шигъри юллар да очраштыргалый. Төрки әдәбият инде X-XI йөзләрдә, аеруча Караханилар дәүләтендә, ныклап үсеп китә. Моңа бу мәмләкәттәге икътисади-иҗтимагый шартлар, сәүдә-һөнәрчелекнең үсеше, шәһәр тормышы зур йогынты ясый. Мәхмүд Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» исемле күләмле китабы (1072-1074) – борынгы төрки рухи тормышының фольклорын, язма әдәбиятын, мифологиясен, телен, фәнен үзенә туплаган гаҗәеп кыйммәтле хәзинә. Анда Идел-йортка, болгар-татарларга мөнәсәбәтле язмалар да бар. Шушы ук чорда Йосыф Баласагунлының атаклы «Котадгу белек» поэмасы (1069) иҗат ителә. Тирән мәгънәле, афористик яңгырашлы бу әсәр үз чорында да, үзеннән соңгы гасырларда да төрки дөньяның «шаһ китабы» вазифасын үти. Аның үзеннән соңгы әдәбиятка, шул исәптән татар сүз сәнгатенә дә йогынтысы гаять зур була.

Диннең рухи тормышта, әдәбиятта мөһим роль уйнавы күптәннән мәгълүм. Борынгырак чорларда безнең әби-бабаларыбыз төрле диннәр тотканнар. Әмма VII-VIII гасырлардан башлап алар арасында мөселман дине тарала башлый, һәм бераздан ул төрки дөньяда, шул исәптән Идел-йортта да төп дингә әверелә. Элеккеге рухи, әхлакый, инсани кыйммәтләр ислам дине белән яраклаштырыла. Коръән тәгълиматы төрки рухи тормышына, аеруча сүз сәнгатенә гарәп-фарсы мәдәни казанышларының ныклап керүенә юл ача. Төрки-татар әдәбиятының соңгы меңъеллык тарихы мөселман дине белән

турыдан-туры, табигый бәйләнешле. Күп кенә сюжет-мотивлар, образ-сурәтләр шигъри детальләр Коръәннән алып эшкәртелә. Изге китап юнәлеш, бәя-хөкем бирү вазифасын да үти. Йосыф Баласагунлыдан алып Тукайгача кадәр яшәгән күпчелек төрки әдипләре ислам дине рухында, мөселман тәгълиматы кысаларында иҗат итә.

«Котадгу белек» традицияләре алдагы гасырда Әхмәт Йүгнәки, Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганыйлар тарафыннан уңышлы дәвам иттерелә. Бу өч шагыйрьнең тәүгесендә дөньявилык, ә соңгы икесендә дини-суфыйчыл карашлар өстенлек итә. Һәм Әхмәд Ясәви (1166 елда вафат була), һәм Сөләйман Бакырганый (үлеме – 1186 елда) илаһи мәхәббәт хисләрен җырлыйлар; матди байлыкка, хакимияткә кызыкмау, күңелне пакьләү, Коръәнгә тугрылык саклап яшәү – алар иҗатындагы төп мотивлар. Бу авторларның әсәрләре өчен шигъри камиллек, музыкаль яңгыраш хас. Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый иҗатлары күп гасырлар буе төрки-татар укучысын рухи яктан туендырып, азыкландырып тора, Хисам Кятиб, Колшәриф, Мәүла Колый, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай һәм башка бик күп әдипләребезгә зур йогынты ясый.

Әдәби барыш, кагыйдә буларак, чагыштырмача дәвамлы, бердәм процесс. Әмма иҗтимагый-социаль шартларга, эчке һәм тышкы факторларга нисбәтән, ул билгеле бер сыйфади үзгәрешләр, үсеш баскычлары кичерә. «Котадгу белек» төрки әдәбияты тарихында яңа бер этапны – Урта гасыр дип йөртелгән дәверне башлап җибәрә. Кайвакыт аның тәүге 100-150 еллык чорын Урта гасырның беренче баскычы («раннее Средневековье») дип тә атыйлар [3: 12, 23]. Ә инде XIII йөздә, төгәлрәге Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәреннән, төрки-татар сүз сәнгатенең чын мәгънәсендәге Урта гасыр чоры башлана. Моңа кадәрге әдәбиятны, гадәттә, төрки кавемнәрнең уртак мирасы дип йөртү кабул ителгән. Ул соңрак үсеп китәчәк милли төрки әдәбиятларның нигезен, төп чыганагын тәшкил итә. Әмма билгеле бер этник, төбәк аерымлыклары инде XII-XIII йөзләргә кадәр үк тә күзәтелә. Мәсәлән, «Котадгу белек»тә уйгыр кавеменең, Караханилар мәмләкәтенең йогынтысы сизелә. Ә инде Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакырганый шигырьләрендә Урта Азия төркиләренең теле, яшәү рәвеше, табигате, мифологиясе билгеле бер эз калдыра. Кызганыч ки, борынгы хәзәр, бәҗәнәк, кимәк кавемнәренә мөнәсәбәтле язма әдәби истәлекләр сакланмаган. Бәлкем, аларда бу кабиләләрнең аерым сыйфатлары да гәүдәләнеш тапкан булгандыр?!

XII-XIII йөзләрдә төрки дөньяның Урта Азия, Идел-йорт, Кавказ арты, Себер-Алтай төбәкләрендә билгеле бер этник, иҗтимагый-мәдәни үзенчәлекләр ныграк оеша башлый. Карахани, Сәлҗүк, Болгар, Кимәк-кыпчак дәүләти берләшмәләр бу процесска уңай йогынты ясый.

Мәгълүм ки, Чыңгыз хан һәм аның варислары тарафыннан Евразиядә үткәрелгән масштаблы сәясәт аеруча төрки дөньяда тирән үзгәрешләр китереп чыгара. Җучи, Чыгытай улуслары төзелү, Госманлы мәмләкәте оешу, Тимериләр дәүләте барлыкка килү этник, иҗтимагый, мәдәни барышка да шактый гына эзен сала. Кече Азиядә Шәйяд Хәмзә (XIII йөзнең икенче яртысы), Йунус Әмрә (1250-1321), Солтан Вәләд (1226-1326), Гашыйк Паша (1271-1332) иҗатларында әкренләп төрек-госманлы сүз сәнгате оеша башлый. Алга таба бу традиция Әхмәди (1329-1413), Шәйхи (1371-1431), Мөхәммәд Чәләби (1358-1451) һәм башка авторлар тарафыннан дәвам иттерелә.

Дөрбәк һәм Хәйдәр Харәзми (XIV йөзнең икенче яртысы – XV гасыр башы), Лотфый (1366-1465), аеруча Нәваи (1441-1501) тырышлыгы нәтиҗәсендә, Урта Азиядә төрки-үзбәк әдәбияты шәкелләшә һәм ныклап үсеп китә. Төрки-әзербайҗан сүз сәнгате үзенең оешып китүендә шактый дәрәҗәдә Нәсими (1369-1417), Физули (1494-1556) эшчәнлекләренә бурычлы.

Әмма төрки кавемнәр, аларның әдәбиятлары билгеле бер дәрәҗәдә этник шәкелләшү, оешу юнәлешен алгач та, үзара керешүләр, гомуми уртаклыклар дәвам итә. Мәсәлән, Алтын Урда җирлегендә яшәгән һәм иҗат иткән Рабгузый, Харәзми, Әхмәд Үргәнчи әсәрләре һәм үзбәк, һәм татар әдәбияты кысаларында карала. Этник чыгышы ягыннан Әстерхан татарлары («нугайлары») белән бәйләнешле мәшһүр Суфый Аллаяр (1616-1713) Урта Азия һәм Идел-йорт төркиләренең уртак шагыйре хисаплана. Аның «Морадел-гарифин», «Сөбател-гаҗизин» поэмалары берничә буын татар зыялыларының өстәл китабы була, соңгысы Таҗеддин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» әсәренең нигезенә салына.

* * *

Башка төрки әдәбиятлары кебек үк, татар сүз сәнгате дә борынгы төрки мирастан, рухи хәзинәдән үсеп чыга. Аның гомуми планда гына булса да шәкелләшә, оеша башлавы XII-XIII йөзләргә карый. Бу әдәбиятның тәүге вәкилләреннән берсе Идел-йортта яшәгән һәм иҗат иткән Дауд Сөләйман Саксини (XII гасыр) була. Әмма, үкенечкә, аның төрки телдә язылган әсәрләре сакланмаган диярлек. Бу авторның гарәп телендә иҗат ителгән, төрле сюжет-хикәятләрне үзенә туплаган җыентыгы да һаман гыйльми, гамәли кулланылыштан читтә кала килә.

Фәндә татар (болгар-татар) әдәбиятын Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» (1212-1233) әсәреннән башлап китү киң таралыш тапкан.

Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятларына, шул исәптән төрки-татар сүз сәнгатенә хас сыйфатларның берсе – әкият-легендаларга, моңа кадәр теге яки бу дәрәҗәдә эшкәртелгән билгеле сюжетларга нигезләнеп, әсәрләр иҗат итү. Биредә сюжет, образ яңалыгыннан бигрәк, аларның ничек, ни рәвешле эшкәртелүе, шәрехләнүе мөһим. «Кыйссаи Йосыф» китабы да – нәкъ әнә шул юнәлештә, элеккеге традицияләр рухында туган күренеш. Аның нигезенә борынгы мифологиядән, Тәүрат, Коръәннән, күп кенә гарәп-фарсы авторларының әсәрләреннән килә торган Йосыф сюжеты һәм образы салынган. Кол Гали үзенә кадәрге булган материалларны эшкәртеп, иҗат казанында кайнатып, оригиналь яңгырашлы әсәр тудырган. Шактый мавыктыргыч, тирән мәгънәле бу шигъри романда камил инсан, хөкемдар һәм халык, яшәүнең асыл максаты һәм бик күп төрле мөһим мәсьәләләр гәүдәләнеш тапкан. «Кыйссаи Йосыф» инде менә 8 гасыр буена халкыбыз белән бергә яши, тормыш дәреслеге вазифаларын үтәп килә. Аның тәүге басмасы 1839 елда Казанда дөнья күрә. Моннан соңгы вакытта «Кыйссаи Йосыф» 100 мәртәбәгә якын нәшер ителә. Аның башка әдәбиятларга, авторларга да тәэсир-йогынтысы зур була.

Алтын Урда чоры, ягъни XIII гасырның урталарыннан XV йөзнең урталарына кадәрге еллар – татар тарихының һәм Урта гасыр татар сүз сәнгатенең бик тә мөһим, бик тә үскән дәвере. Бу чорда халкыбыз, төрле этник төркемнәр кушылуыннан оешып, дөньяга татар исеме белән мәгълүм була. Җучи олысы – Урта гасыр Евразия тормышында гаять әһәмиятле роль уйнаган кодрәтле мәмләкәт. Ул икътисади, сәяси яктан гына түгел, гыйльми, мәгърифәти, мәдәни җәһәттән дә зур уңышларга ирешә. Шәһәр тормышы кайнап тора. Бик күп илләр һәм халыклар белән төрле багланышлар урнаша. Аеруча Мисыр белән элемтәләр көчле була, чөнки анда ике гасырдан артык Идел-йорттан чыккан мәмлүкләр идарә итә, төрки-татар теле киң кулланылышта йөри.

Алтын Урдага мөнәсәбәтле бай рухи, әдәби мирасның бик аз өлеше генә сакланып калган. Аерым ярлыклар, сүзлекләр, эпитафик истәлекләр, фәнни язмалар билгеле. Бу чор язма истәлекләреннән төп урынны әдәби әсәрләр алып тора. Алар кыйсса, хикәят, газәл, касыйдә, дастан, шигъри роман, робагый һәм кайбер башка жанрларда иҗат ителгән. Тезмә, чәчмә, катнаш әсәрләр бар.

Алтын Урда чоры һәм, гомумән, ислам чоры төрки-татар сүз сәнгатен тиешенчә аңлау, бәяләү өчен, бик тә мөһим бер күренешне искә алып китү зарури. Билгеле булганча, төрки-татар сүз сәнгате мең елдан артык яшәү дәверендә үз кысаларында гына яшәми, башка кавемнәрнең рухи байлыклары белән дә мөнәсәбәткә керә. Иң озын-озак багланышлар, әлбәттә, гарәп-фарсы дөньясы белән була. Мәгълүм ки, ислам дине кабул ителгәч, гарәпләр, бераздан фарсылар бик нык алга китәләр, аларның телләрендә искиткеч бай әдәбият туа. Шунысы мөһим: гарәп, фарсы авторлары, бер яктан, үзләренең борынгы мәдәниятләренә таянсалар, икенче яктан, антик Греция, Рим казанышларын, Һиндстанның рухи кыйммәтләрен мул һәм иҗади үзләштерәләр.

Дини уртаклык, үзара аралашулар, телләрне белү нәтиҗәсендә, безнең әби-бабаларыбыз гарәп-фарсы рухи казанышларыннан хәбәрдар булалар. Шәрык классик әдәбияты Идел-йортта киң таралыш таба: оригиналда укыла, төрле тәрҗемә-шәрехләр эшләнә, төрки-татар сүз сәнгате үсешенә зур йогынты ясый. Бу Алтын Урда чоры әдәбиятында ачык күренә. Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» (1310), Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (1358) китапларында гарәп, фарсы телләрендәге материаллар, сюжетлар һәм образлар мул файдаланылган. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» романы (1342) Низаминың фарсы телендәге әсәре нигезендә иҗат ителә. Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки»е (1391) Сәгъдинең «Гөлестан»ына барып тоташа. Шунысы әһәмиятле: төрки-татар авторлары оригиналга иҗади якын киләләр: өстәмә-төзәтмәләр кертәләр, үз укучыларының ихтыяҗларына

аваздаш эш итәләр. Котб, Сәйф Сараи әсәрләре фәндә мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия ядкәрләр буларак карала.

Алтын Урда чоры төрки-татар әдәбиятына идея-тематик байлык, сәнгати камиллек хас. Авторлар кеше тормышының, чынбарлыкның күп төрле мәсьәләләрен гәүдәләндерәләр. Котб, мәсәлән, мәхәббәт темасы аркылы иҗтимагый-социаль проблемаларны яктырта. Аның фикеренчә, олы мәхәббәт хисләренә ия булган хөкемдар гына үзенең җитәкчелек вазифаларын тиешле югарылыкта башкара ала. Роман каһарманнарыннан берсе булган Фәрһад үзенең ташчылык хезмәтеннән тәм һәм ямь таба. «Хөсрәү вә Ширин» әсәре өчен билгеле бер синкретизм да хас. Анда галәм төзелеше, яшәешкә хас диалектик хәрәкәт, җәмгыять хакында кызыклы фикер-күзәтүләр бар. Харәзми иҗатында мәхәббәтнең иң бөек, олы хис булуы җырлана. Лирик герой үз яшәешенең асыл максатын, мәгънәсен мәхәббәттә күрә. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастанында (1369) тормыш, яшәеш хакында тирән фәлсәфи күзәтүләр ясала. Бу дөньяда «бер мең», тәмугта «дүрт мең» ел булган Җөмҗөмә язмышы аркылы [4: 168] автор яшәүнең мәгънәсе байлык-тәхеттә түгел, ә гаделлектә, иманда икәнлеген ассызыклый. Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастаны композицион-структур яктан Рим шагыйре Вергилийның (Яңа эрага кадәр 70 еллар – безнең эраның 19 елы) «Энеида»сын, Ф.Гаттарның (1119-1223) «Җөмҗөмәнамә»сен, итальян әдибе Данте Алигьериның (1265-1321) «Илаһи комедия»сен искә төшерә. Аларның һәрберсе теге һәм бу дөнья күренешләрен үреп сурәтләүгә, төп геройның җир астына (тәмугка...) сәяхәт кылуына нигезләнгән. Әдәби вакыт һәм урынның, ягъни хронотопның шартлы рәвештә, масштаблы бирелүе авторларга үзләре әйтергә теләгән фикерне үтемле итеп җиткерүгә ярдәм иткән.

Алтын Урда әдәбиятында билгеле бер күләмдә тормыш-чынбарлыкка якынаю, андагы вакыйга-хәлләр белән турыдан-туры кызыксыну да күзәтелә. Котб һәм Харәзми әсәрләрендә Алтын Урда хөкемдарлары Тенибәк һәм Мөхәммәд Хуҗа бәк образлары гәүдәләндерелә. Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» дастанында (1394) егет белән кызның һәлакәте Аксак Тимер сәясәтенең аянычлы нәтиҗәсе рәвешендә кабул ителә.

Ике гасыр яшәгәннән соң Алтын Урда дәүләте эчке һәм тышкы каршылыклар нәтиҗәсендә төрле ханлыкларга таркала. Аның нигезендә Кырым, Казан, Әстерхан, Олы Урда, Нугай, Себер мәмләкәтләре барлыкка килә. XV гасыр урталарында Касыйм ханлыгы да оеша. Бу дәүләтләр икътисади, иҗтимагый, сәяси, мәдәни яктан Алтын Урда традицияләрен дәвам итәләр. Алардагы халыкның төп өлешен безнең әби-бабаларыбыз тәшкил итә. Шуңа мөнәсәбәттә бу дәүләтләрне еш кына татар ханлыклары дип йөртәләр. Татар теле аларда төп аралашу һәм язма тел вазифасын үти. Гарәп, фарсы һәм башка төрки телләр дә зыялылар, дәүләт түрәләре тарафыннан кулланыла.

Алтын Урда чоры кебек, Казан ханлыгы дәверенең дә тик бер өлеш язма истәлекләре генә безгә килеп ирешкән. Алар арасында Ибраһим һәм Сәхибгәрәй хан ярлыклары, Мөхәммәд Әмин ханның Польша короле Александрга хат-бетеге, Коръән тәфсире, каберташ язмалары, әдәби әсәрләр һ.б.лар бар. Шушы чорда татар теленә атаклы «Кәлилә вә Димнә» җыентыгы тәрҗемә ителә [5][1]. Әтнәш Хафиз 1554 елда «Сиражел-колуб» әсәрен төгәлли. Дини-әхлакый рухтагы бу китап иман ныклыгын, вөҗдан сафлыгын саклауга юнәлтелгән. Атаклы «Идегәй» дастаны да татар ханлыклары төзелү чорында оеша башлый. Казан ханлыгы дәверендә татар әдәбияты, гәрчә Алтын Урда чорындагы кебек үк булмаса да, билгеле бер үсешкә ирешә. Төрле төрләрдә һәм жанрларда әсәрләр иҗат ителә. Нигездә, традицион темалар эшкәртелә. Тормыш юлы Идел-йорт, Кырым, Кече Азия белән бәйләнешле Өмми Кәмал[2] иҗаты тулысы белән суфыйчылык рухы белән сугарылган. Аның фикеренчә, һәр туган нәрсә үлемгә хөкем ителгән. Бар да вакытлы, фани; адәм баласына гомер үзен теге дөньяга әзерләү өчен бирелгән. «Үлмәстән борын үлеп куй» – бу яшәешнең төп принцибы. Өмми Кәмал иҗатында, нәкъ Ясәвидәге кебек, илаһи мәхәббәт хисләре җырлана. Аның әсәрләре халыкта киң таралыш таба, әдәбиятка билгеле бер йогынты ясый.

Колшәриф – рухани, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе генә түгел, Казан ханлыгының күренекле шагыйре дә. Аның дини-суфыйчыл

[1] Шунысын да искәртик: бу атаклы китап күп гасырлар буе укучыларыбызның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндереп килә. С.Сараи, Мөхәммәдьяр, К.Насыйри, Г.Тукай, М.Гафури һәм кайбер башка авторлар өчен яңа әсәрләр иҗат итүдә материал, сюжет чыганагы булып хезмәт итә.

[2] Исмәгыйль. 1475 елда вафат була.

рухлы сәнгати камил шигырьләре болай да, «Бакырган китабы» дип исемләнгән җыентык аша да укучыларга яхшы мәгълүм. Бу зат илнең иминлеген саклауга зур өлеш кертә, ахыр чиктә үз Ватаны – Казан мәмләкәте белән бер үк вакытта һәлак тә була. Шәрифинең[3] «Зафәрнамәи вилаяти Казан» исемле әдәби-тарихи характердагы язмасы (1550) Казан мәмләкәте, аның бәйсезлек өчен көрәше хакында бай мәгълүмат бирә. Әсәр Явыз Иван баскынчыларына каршы нәфрәт рухы белән сугарылган. Бу язмада Казан шәһәре турында тирән мәгънәле шигъри юллар да урнаштырылган.

Мөхәммәдьяр Мәхмүд Хаҗи углы (1497-1549) – Казан ханлыгы чорының иң күренекле шагыйре. Аның ике поэмасы («Төхфәи мәрдан», 1539; «Нуры содур», 1542) һәм «Нәсыйхәт» исемле символик эчтәлекле шигыре билгеле [6]. Алар әхлакый-иҗтимагый характерда. Поэмалары тартмалы композицион жанрда, ягъни чагыштырмача мөстәкыйль хикәят-сюжетлар, композицион берәмлекләр тупланмасыннан гыйбарәт. Автор шигъри юллар ярдәмендә инсаннарны пакьләргә, гөнаһларыннан арындырырга, җәмгыятьтә чын инсани мөнәсәбәтләр корырга омтыла. Урта гасырның күп кенә башка әдипләре кебек, Мөхәммәдьяр да шигъри сүзнең көч-кодрәтенә ышана, аңа зур өметләр баглый. Аның фикеренчә, тел – «тылсым ачкычы», адәмнең бөтен гамәле телгә, сүзгә бәйле [6: 205-206]. «Сүзләмәкдә сән йөземне ак кыл, Сүзләремне ил күңлигә йомшак кыл» [6: 41] – бу юллар шагыйрь иҗатының кыйбласы, асыл максаты.

Совет чорында Идел буе һәм Кырым татарлары, аларның әдәбияты ничектер, ясалма рәвештә еш кына аерым каралды. Ә бит бу кавемнәр бер-берсе белән бик тә тыгыз бәйләнешле. Алтын Урда чорында алар бер үк дәүләт составында яшиләр, телләре, килеп чыгышлары, сүз сәнгатьләре уртак. Мондый гомумилек татар ханлыклары чорында да дәвам итә. Әмма XVI йөздән, аеруча Казан, Әстерхан ханлыклары бетерелгәч, Кырым мәмләкәтенә Госманлы дәүләтенең йогынтысы көчәя. Бу аның теленә, сәнгатенә, гореф-гадәтләренә билгеле бер эз сала. Шуңа да карамастан, Идел-йорт һәм Кырымда яшәүчеләр олуг татар дөньясының вәкилләре булып кала киләләр.

Мәгълүм ки, Кырым ханлыгы, башка татар мәмләкәтләре бетерелгәч тә, ике гасырдан артык, ягъни 1783 елга кадәр яшәвен дәвам итә. Анда гомумтатар мәдәниятенең күп кенә традицияләре дәвам иттерелә. Шактый гына әдәби әсәрләр языла [1: 42-45]. Әмма, кызганыч ки, алар безнең әдәбият тарихы китапларында, дәреслек-антологияләрдә чагылыш тапмаган диярлек. Бары талантлы шагыйрь Гашыйк Гомәр (1621-1707) хакында гына азмы-күпме мәгълүматлар китерелә [1: 194-198]. Ул, бер яктан, элеккеге төрки-татар әдәби традицияләрен уңышлы дәвам иттерсә, икенче яктан, Шәрык, аеруча госманлы сүз сәнгате казанышларын иҗади файдалана.

* * *

XVII-XVIII йөзләр – Урта гасыр татар әдәбиятының соңгы чоры («Позднее Средневековье»). Ул халкыбыз тарихының бик тә фаҗигале, авыр һәм катлаулы дәвере. Күп гасырлар буе дәүләт тоткан татарлар Идел-йортта, үз мәмләкәтләрен югалтып, колониаль изелүгә дучар ителәләр. Халыкның күбесе кырыла, башка җирләргә, илләргә күчеп, качып китәргә мәҗбүр була. Матди һәм мәдәни байлыкларның зур өлеше юк ителә, илбасарлар тарафыннан үзләштерелә. Көчләп чукындыру, урыслаштыру Россия империясенең күпгасырлык рәсми сәясәтенә әверелә. Милли, социаль һәм колониаль изелүгә каршы татарлар күп мәртәбәләр көрәшкә күтәрелә. Әмма аларның һәммәсе рәхимсез рәвештә бастырыла. Әмма нинди генә зур кыенлыклар, фаҗига-афәтләр булуга да карамастан, татарлар китаптан аерылмый, яшь буынны белемле итәргә тырыша. Халыкта элек иҗат ителгән Кол Гали, Рабгузый, Мәхмүд Болгари, Мөхәммәдьяр әсәрләре, гарәп, фарсы, төрки дөньясыннан кергән китаплар укылуын дәвам итә. Колониаль изелүнең тәүге дистә елларында, тиешле шартлар булмау аркасында, яңа әдәби әсәрләр иҗат ителми диярлек. Фаҗигале хәлләр уңае белән аерым бәетләр туа. XVII гасырда инде әдәбиятта азмы-күпме аерым ядкәрләр күренә башлый. Алар арасында һәм оригиналь, һәм тәрҗемә әсәрләр бар.

Кадыйр Галибәкнең «Җәмигъ эт-тәварих» (1602), билгесез авторның «Дәфтәре Чыңгызнамә» (1679-1685), Хисамеддин Мөслиминең «Тәварихе Болгария» кебек язмаларын ярымтарихи, ярымәдәби ядкәрләр исемлегенә кертеп йөртәләр. Аларда, аерым тарихи вакыйгалар, факт-мәгълүматлар белән бергә, легенда-риваятьләр, әкияти материаллар да урын алган. Бу әсәрләр өчен билгеле бер

[3] Шәриф Хаҗитархани. Аны кайберәүләр Колшәриф белән дә тиңлиләр.

дәрәҗәдә интертекстуальлек, эклектизм, синкретизм да хас.

Шигърияттә XVII йөзнең икенче яртысында Мәүла Колый мөһим урынны били. Ул, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый традицияләрен дәвам итеп, нигездә, хикмәт жанрында яза. Аның хикмәтләре өчен афористик яңгыраш, тормышчанлык хас. Еш кына Мәүла Колыйны суфый шагыйрь дип йөртәләр. Чыннан да, ул илаһи гыйшык турында яза, суфый булырга омтылышын да искәртә. Әмма аның суфыйлыгы камил инсан, идеал кеше төшенчәсе белән керешеп китә. Автор җитештерүчән хезмәтне яклый, гаилә коруны, бала тәрбияләүне, гыйлем туплауны һәркемнең зарури эше дип саный. Мәүла Колый фикеренчә, игенчелек иң «гали» (бөек, олы) эш. Шагыйрь үз укучыларын иген игәргә чакыра. Аның карашынча, игенчелек белән шөгыльләнгән кешенең урыны – җәннәттә. Урта гасырның башка әдипләре кебек, Мәүла Колый да белем-мәгърифәтне зурлый, наданлыкны, антитеза алымы белән, кискен тәнкыйтьли. Аның традицияләрен XVII-XVIII гасырлар аралыгында иҗат иткән Габди дәвам иттерә. Ул үзенең шигырьләренә сөйләм элементларын, аваз ияртемнәрен, төрле кабатлауларны уңышлы гына кертеп җибәрә. Мәсәлән,

Атаң берлә анаңа хезмәт иткел күп-күп,
Иртә торгыл, һәр көндә аякларын үп-үп.
Һәр ни әйтсә, анларның сүзләрен күп йөп-йөп.
Сабыр кыйлгыл, һәр нәчә кыйнасалар «дөп-дөп» [7: 403].

XVIII йөз татар әдәбиятында билгеле бер җанлану, үсеш күзәтелә. Авторларның, иҗат ителгән әсәрләрнең саны да арта, кулланылган жанрлар да күбәя, төрләнә. Оригиналь әсәрләр белән бергә, тәрҗемәләр дә күзгә ташлана. Гомумән, бу чор сүз сәнгатендә шул чор татар чынбарлыгына игътибар көчәя. Бу аеруча мәдхия-мәрсияләрдә, сәяхәтнамәләрдә, Батырша язмаларында күзгә ташлана.

Батырша Баһадиршах углы Галиев (1710-1762) – 1754-1755 елгы татар-башкорт кузгалышының җитәкчесе. Ул патша хакимияте тарафыннан кулга алына. Мәскәү, Санкт-Петербург зинданнарында газап чигә. Төрмәдә вакытта ул патша исеменә «Гарызнамә» яза. Публицистик рухлы бу ядкәрдә автор крестьян хәрәкәтенең сәбәпләрен, түрәләрнең комсызлыгын яктырта. Батырша язмасы Россиянең колониаль сәясәтен гаепләү акты буларак та кабул ителә. Исмәгыйль Бикмөхәммәд углының Урта Азиягә, Һиндстанга, Гарәбстанга сәфәрен чагылдырган язмасы фактик материалга байлыгы, кызыклы күзәтүләре белән аерылып тора. Шушындый ук сыйфатлар Мөхәммәд Әмин сәяхәтнамәсе өчен дә хас. Аның төп эчтәлеген Казаннан Әстерхан, Төньяк Кавказ, Истанбул аша хаҗга бару һәм кайтуны сурәтләү тәшкил итә.

XVIII йөздә дистәләгән шагыйрьнең иҗат итүе мәгълүм: Габделмәннан Мөслим углы (Мәндан) Әхмәдбик, Хөсәен бине Локман, Рәхимкол Әбүбәкер углы, Нигъмәтулла Бәшир углы һ.б. Болар арасында аеруча Габдессәлам (1700-1766 дан соң) аерылып тора. Чыгышы белән ул Казан артыннан, Ташкичү мәдрәсәсендә укый, эшли. 1746 елда Оренбург Каргалысына күчеп китә. Биредә мәчет-мәдрәсәләр салдыра, шәкертләр тәрбияли. Габдессәламнең халык җырлары, бәетләре рухында язылган «илаһи бәетләре» халыкта бик киң тарала, хәтта кайберләре фольклорлашып та китә. Алар өчен эмоциональлек, нечкә лиризм хас. Габдессәламнең аерым шигырьләрен үз вакытында Г.Державин урыс теленә дә тәрҗемә итә.

XVIII йөздә татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрдән «Мәҗмугыл-хикаят» җыентыгы игътибарга лаек. Ул фарсычадан күчерелгән. 33 хикәятне туплаган бу җыентык өчен маҗаралылык, дөньявилык хас. Анда тапкырлык, зиһенлелек хуплана. Шунысы кызыклы: татарча «Мәҗмугыл-хикаят»кә нигез булган фарсыча җыентык 1710-1712 елларда Пети де ля Круа дигән француз әдибе тарафыннан французчага шактый ирекле тәрҗемә ителә. «1001 көн» исемен алган бу китап үз чиратында күп кенә Европа телләренә, шул исәптән русчага да күчерелә, йөзәрләгән сәнгать әсәрләрен иҗат итүдә материал рәвешендә файдаланыла. Алар арасында итальян композиторы Д.Пуччининың атаклы «Турандот» операсы да бар.

Әдәбият тарихының чорларга бүленеше – чагыштырмача шартлы күренеш, чөнки чор, дәверләр еш кына үзара табигый керешеп китә. Татар әдәбиятының «урта гасыр» дип йөртелгән өлешендә дә бу еш күзәтелә. XVIII йөз белән XIX гасыр бер-берсе белән тыгыз бәйләнешле. Аерым әдипләрнең иҗаты бер чордан икенчесенә күчеп китә. Бу Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834) һәм Таҗеддин Ялчыгол (1763/1768-1838) мисалында аеруча ачык күренә. Бу әдипләрнең һәр икесе дә XVIII

йөзнең икенче, XIX гасырның беренче яртысында яшәгәннәр һәм иҗат иткәннәр. Шуңа мөнәсәбәттә аларны һәр ике чорда да өйрәнү күзәтелә. Аларның әсәрләре вакыт ягыннан гына түгел, эчтәлек, сыйфат ноктасыннан да Урта гасырдан XIX йөз мәгърифәтчелек әдәбиятына күчеш характерында. Утыз Имәни әсәрләрендә, бигрәк тә аның хатыны Хәмидәгә багышлап язган мәрсияләрендә реалистик әдәбиятка хас элементлар, детальләр күзгә ташлана. Һәр ике автор да белем-мәгърифәтне, гамәл кылуны зурлый, әхлаклылыкны яклый.

Утыз Имәни – энциклопедик эшчәнлеккә ия зат. Ул төрле тармакларда хезмәт куйган, иҗтимагый тормышта актив катнашкан. Аның төрле жанрларда иҗат ителгән күп санлы шигъри әсәрләре, шул исәптән күләмле поэмалары бар. Таҗеддин Ялчыгол барыннан да элек үзенең «Рисаләи Газизә» әсәре белән мәшһүр. Ул күп мәртәбәләр басылган, мәктәп-мәдрәсәләрдә әсбап рәвешендә кулланылган.

* * *

Мең еллап вакытны үз эченә алган Урта гасыр төрки-татар сүз сәнгате гомумтөрки карынында туып, үз үсешендә төрле баскычларны, этапларны үткән. Аның иң күтәрелгән дәвере – Алтын Урда чоры.

Урта гасыр төрки-татар сүз сәнгате – нигездә, мөселман дине рухы белән сугарылган әдәбият. Ул Шәрык классикасының көчле тәэсирендә яши һәм үсә. Шактый гына сюжет-мотивлар, сурәтләр, әдәби күренешләр генетик яктан гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларга барып тоташа. Урта гасыр төрки-татар сүз сәнгатендә шигърият өстенлек итә. Чәчмә, катнаш әсәрләр дә шактый урынны били. Авторлар гаруз шигырь төзелешенә, хикәят, дастан, кыйсса, газәл, робагый, тартмалы композиция кебек жанрларга ныграк игътибар итәләр. Язма телдә гарәп, фарсы алынмалары, борынгы формалар шактый зур урынны били. Сурәтләүдә антитеза, гадәттән тыш арттыру яисә киметү, традиционлык, интертекстуальлек, шартлылык еш кулланыла. Билгеле сюжет-мотивларны, образларны файдаланып, әсәрләр язу киң таралыш таба. Алла һәм кеше, табигать һәм инсан мөнәсәбәтләрен яктырту, әхлакый, дини-суфыйчылык тематикаларын эшкәртү үзәктә. Күпчелек әсәрләрдә белем-мәгърифәт, хезмәт-һөнәр, мәхәббәт мактала. Камил инсан, мәгърифәтле, гадел хөкемдар проблемасы да эшкәртелә.

Без Урта гасыр төрки-татар әдәбиятының чыганакларына, төп баскычларына, әйдәп баручы авторларына, үзара бәйләнешларына тукталдык. Бу чор әдәби процессының төп тенденцияләре, аерым поэтик хосусиятләре ачыкланды. Жанрлар хакында да сүз булды. X-XVIII йөзләрне үз эченә алган Урта гасыр әдәбияты гаять бай, күп төрле. Бу язмада исә аның кайбер мөһим яклары, күренешләре генә телгә алынды.

Урта гасыр сүз сәнгате – озын-озак тарихлы татар әдәбиятының бик тә әһәмиятле бер дәвере. Аның казанышлары, XIX йөздә тагын да баетылып, үстерелеп, XX гасыр башында бөек Г.Тукайлар, Г.Исхакыйлар җитлегүгә зур йогынты ясады. Урта гасыр татар сүз сәнгате башка әдәбиятлар үсешендә дә билгеле бер роль уйнады.

**Әдәбият**


1. *Миннегулов Х.Ю.* Этапы развития тюрко-татарской, античной и русской литератур. Казань: Ихлас, 2014. 288 с.
2. *Паркер Э.Х.* Тысяча лет из истории татар. Второе издание, переработанное. Казань: Идел-Пресс, «Слово», 2003. 288 с.
3. *Миннегулов Х.Ю.* Тюркское словесное искусство. Казань, 2014. 62 с.
4. Борынгы төрки һәм татар әдәбиятының чыганаклары / Төз.: Х.Госман. Казан: Казан дәүләт ун-ты, 1981. 246 б.
5. Кәлилә вә Димнә / Төз.: Җ.Зәйнуллин. Казан: Мәгариф, 1996. 271 б.
6. *Мөхәммәдьяр.* Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 331 б.
7. *Абилов Ш.Ш.* Габди // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. Т. 1: Урта гасырлар дәвере. Казан: Татар. кит.нәшр.,1984. Б.399-404.

# ТЮРКО-ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА СРЕДНЕВЕКОВЬЯ

**Хатип Юсупович Миннегулов,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г.Казань, ул.Кремлевская, д.18,
tgilazov@bk.ru.

Тюрко-татарская литература X-XVIII столетий, то есть периода Средневековья, возникла на основе древнетюркского словесного искусства и фольклора. В ее развитии большую роль сыграли арабо-персидская классика, а также уйгурская, османская, узбекская и некоторые другие тюркоязычные литературы. В статье освещаются основные этапы в истории тюрко-татарского словесного искусства Средневековья (раннее и позднее Средневековье, болгарский, золотоордынский, Казанский и другие периоды), анализируется творчество ведущих писателей, выявляются основные тенденции литературы Средневековья и ее поэтические особенности.

**Ключевые слова:** тюрко-татарская литература, устное народное творчество тюркских народов эпохи Средневековья, арабо-персидская классика, Восток, этапы развития тюрко-татарской литературы, литературные связи, жанры.